ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____08.09.2026______ Мөслим ав. № __327___

**«Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 3 ноябрендәге 495 номерлы Башкарма комитет карарына үзгәреш кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 3 ноябрендәге 495 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 2.8.2.1 пунктының 6 пунктчасында «линия объектлары булган инженерлык корылмаларына капиталь ремонт ясау максатларында, шулай ук мондый инженерлык корылмаларының участокларына (өлешләренә) капиталь ремонт ясау максатларында гавами сервитут билгеләү очрагыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru/)

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И. Ф. Салихҗанов